КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 24 сентябрь г.Казань № 825

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 31 октябрь, 980 нчы карары белән расланган Муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан муниципаль заданиене үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү өлешендә халыкның ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәт күрсәтүләрен тәэмин итү өчен шартлар тудыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә бар-лыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджет-ларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан муниципаль заданиене үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү өлешендә халыкның ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәт күрсәтүләрен тәэмин итү өчен шартлар тудыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 31 октябрь,

980 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 26 март, 188 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан муниципаль заданиене үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү өлешендә халыкның ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәт күрсәтүләрен тәэмин итү өчен шартлар тудыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башка бюджетара трансфертлар түбәндәге очракларда муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә:

агымдагы елда Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы күрсәтмәсе буенча файдалануга тапшырылган күчемсез мөлкәт объектларын муниципаль милеккә тапшырган һәм әлеге күчемсез мөлкәт объектларын муниципаль мәдәният учреждениеләренә оператив идарә итү хокукында беркетелгән очракта;

агымдагы елда федераль мөлкәт белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы карары буенча файдалануга тапшырылган күчемсез мөлкәт объектларын муниципаль милеккә тапшырган һәм әлеге күчемсез мөлкәт объектларын муниципаль мәдәният учреждениеләренә оператив идарә итү хокукында беркетелгән очракта;

муниципаль мәгариф оешмаларына элек беркетелгән күчемсез мөлкәт объектларын муниципаль мәдәният учреждениеләренә оператив идарә хокукында беркеткән очракта;

Татарстан Республикасы дәүләт программалары кысаларында капиталь ремонт үткәрелгән, элек муниципаль берәмлек казнасы мөлкәте составында булган биналарны муниципаль мәдәният учреждениеләренә оператив идарә хокукында беркеткән очракта.»;

10 пунктта:

беренче абзацта «муниципаль берәмлек» сүзләрен «муниципаль берәмлек ($P_i$)» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

11 пунктта:

беренче абзацта «мәдәният учреждениесе» сүзләрен «мәдәният учреждениесе ($N_j$)» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

12 пунктта «норматив хокукый» сүзләрен төшереп калдырырга;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар килешүдә билгеләнгән срокларда муниципаль берәмлекләрнең финанс органнары өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган муниципаль берәмлекләр бюджетларының бердәм счетларына күчерелә.»;

16 пунктта «5есеннән» сүзләрен «бишенче эш көненнән» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткечләрен һәм ел йомгаклары буенча фактта ирешелгән башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткечләрен чагыштырып карау юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

21 пунктның беренче абзацында «бюджетара трансфертлар» сүзләрен «бюджетара трансфертлар (D)» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин